ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 8 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» 2011 елның 10 октябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2015, № 4; 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2) республика башкарма хакимиятенең региональ дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле органын (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт торак күзәтчелеге органы) билгеләү;»;

2) 6 статьяда:
а) исемендә «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимиятенең башка органнары» сүзләренә алмаштырырга;
б) беренче абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;
в) 2 пунктта «, күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту максатларында салкын судан, җылы судан файдалану, агып төшкән суны җибәрү, электр энергиясен куллану нормативларын» сүзләрен «(шул исәптән торак фонды объектларыннан каты көнкүреш калдыклары туплану нормативларын), күпфатирлы йортта гомуми мөлкәттән файдаланганда һәм аны карап тотканда

кулланыла торган коммуналь ресурслардан файдалану нормативларын» сүзләренә алмаштырырга;

3) 7 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле $5^1$ пункт өстәргә:

«$5^1$) муниципаль берәмлектә Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясындагы 19 өлешендә күрсәтелгән иҗтимагый берләшмәләрне, коммерциягә карамаган башка оешмаларны төзүгә һәм аларның эшчәнлегенә ярдәм итәләр;»;

б) 2 өлештә «8 өлешендә» сүзләрен «19 өлешендә» сүзләренә алмаштырырга;

4) 10 статьяның 3 өлешендә «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары» сүзләрен «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2023 ел, 20 июнь
№ 49-ТРЗ